# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Кыр Шонталы авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 12 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кыр Шонталы торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Кыр Шонталы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Кыр Шонталы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2.Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
- җирлек эчендәге юлларны төзекләндерү, карап тоту һәм ремонтлау;
-су белән тәэмин итү системасын карап тоту;;
- торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (фонарьлар сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- техниканы карап тоту: (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт хакы түләү);
- җирләү урыннарын төзекләндерү (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Бөек Ватан сугышында (1941-1945 еллар) һәлак булганнарга һәйкәл территориясен төзекләндерү, ремонтлау, койма белән әйләндереп алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Кыр Шонталы авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Кыр Шонталы авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында

(http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Кыр Шонталы авыл җирлеге башлыгы _______________ Кыямова Г.Н.
(имза)